ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
б) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда «учреждениеләренең, оешмаларының һәм предприятиеләренең» сүзләрен «оешмаларының» сүзенә алмаштырырга;

4) 9 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяның дүртенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 статьяның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы вәкиллекләре үз компетенциясе чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе

Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген координацияләү буенча Татарстан Республикасы Рәисе вәкаләт тапшырган орган кушуы нигезендә түбәндәгеләрне башкаралар:»;

7) 12 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 14 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

9) 15 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

10) 16 статьяда икенче җөмләне төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 105-ТРЗ